Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Березовая Грива торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2020 елның 28 октябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 28 октябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Березовая Грива торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

- Борок авылында янгын сүндерү машинасы өчен гараж төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 87 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 48 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 48 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Березовая Грива торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Березовая Грива торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 2021 елда 300 сум

күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

- Борок авылында янгын сүндерү машинасы өчен гараж төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Каенлы авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Каенлы авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарипов